Тукай муниципаль районы Борды авыл җирлеге Бордыбаш авылы
**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

18 ноябрь 2022 ел № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Бордыбаш авылы гражданнар җыены

**КАРАР БИРДЕ:**

1. «2023 елда яшәү урыны буенча Борды авыл җирлеге Бордыбаш авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 500 (биш йоз) сум күләмендә бер тапкыр түләү кертергә һәм I, II төркем инвалидлары һәм Бөек Ватан сугышы ветераннары, ялгыз яшәүче өлкән яшьтәге гражданнар һәм көндезге формада укучы студентлар, күп балалы гаиләләр өчен бер тапкыр түләү күләмен киметергә һәм аны әлеге категория гражданнар өчен 250 (ике йоз илле) сум күләмендә билгеләргә, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә өлешчә мобилизацияләү буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнарның, Борды авыл җирлеге территориясендә теркәлгән гаилә әгъзаларының үзара салым буенча взносларын түләүдән азат итәргә, әлеге сумманы түбәндәге мәсьәләне хәл итүгә юнәлдерергә:

- Бордыбаш авылы зиратын тозеклэндеру (койма сатып алу hэм урнаштыру).

2. Тукай муниципаль районы Борды авыл җирлеге Бордыбаш авылы гражданнар җыены нәтиҗәсен авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырып, халыкка җиткерергә.

3. Тукай муниципаль районы Борды авыл җирлеге Бордыбаш авылы гражданнар җыены нәтиҗәсен Тукай муниципаль районының рәсми сайтында «авыл җирлекләре» бүлегендә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Борды авыл җирлеге Башлыгы Р.Н.Абдульманова